КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 март г.Казань № 253

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 142 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 142 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 декабрь, 1335 нче; 2023 ел, 30 гыйнвар, 74 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының факттагы йогынтысын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә» сүзләренә алмаштырырга;

4.11 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесенә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин